РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЛАННИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ

**БАЛАННЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**Баланны авылы** **«22» декабрь 2025 ел**

**КАРАР № 5**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы
Баланны авыл җирлеге территориясендә 2025-2026 елларның кышкы
чорында карны вакытлыча җыю урыннарын билгеләү турында**

Интенсив кар яву чорында юлларны һәм урамнарны кардан вакытында чистартуны тәэмин итү, 2025-2026 елларның кышкы чорында Баланны авыл җирлегендә территорияне чистартуны тәртипкә салу һәм вакытлыча кар җыю урыннарын билгеләү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Баланны авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1. 2025-2026 елларның кышкы чорында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланны авыл җирлеге территориясендә вакытлыча кар җыю өчен ачык мәйданчыклар сыйфатында түбәндәге территорияләрне билгеләргә:

Баланны авылында урнашкан 16:29:170401:26 кадастр номерлы җир кишәрлеге янәшәсендәге 300,00 кв. м мәйданлы буш кишәрлектә ;

Шуганка авылында урнашкан 16:29:170501:6 кадастр номерлы җир кишәрлеге янәшәсендәге 100,00 кв. м мәйданлы буш кишәрлектә.

Чия Түбә авылында урнашкан 16:29:170402:8 кадастр номерлы җир кишәрлеге янәшәсендәге 100,00 кв. м мәйданлы буш кишәрлектә

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль берәмлеге рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Мөслим муниципаль районы
Баланны авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе:** **Д.М. Гизетдинов**